47 НЧЕ УРАК

Нурулла Ульданов, техника җене бер кагылса, гомерлеккә, ди

> 2



АКЫЛЛЫ КӨНДӘШ

Аның бик файдалы яклары да, шикшебһә уята торган сыйфатлары да җитәрлек

> 3



ТАТАРЧА КАЙНАУ

Халыкара олимпиада җиңүчеләре киләчәк турында сөйләде

> 3

КЫЙБЛА

«ВТ»ның Татарстанда яшәүче милләтләр турында махсус проекты

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 59 (29026) | Чәршәмбе | 26 апрель | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Эльвира ВӘЛИЕВА

Борчыган мәсьәлә

Илдар Мөхәммәтҗанов

КЫЙММӘТЛЕ ЮЛ

Татарстанда һәр алтынчы авылга диярлек юл юк! Зур юлдан өзелгән салаларны, вак таш түшәп, олы юлга тоташтырмакчылар. Юл кадере турында Татарстан Министрлар Кабинетында узган брифингта сөйләделәр.

Быел Татарстанда юл эшләренә, зур проектларны тормышка ашыруны да исәпкә алып, 250 миллиард сум акча тотачаклар. Бу хакта транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Фәрит Хәнифов әйтте.

– Узган ел белән чагыштырганда, агымдагы елда республикада юл эшләре тагын да кызурак узачак. Былтыр 209 миллиард сумлык эш башкарсак, быел әлеге санны 250 миллиард сумга җиткерү күздә тотыла, – диде министр.

Татарстанның юл эшләре программасына 67 миллиард сумнан артык акча бүлеп биреләчәк. Шуның 14 миллиард сумга якыны федераль үзәккә туры килә. Төп социаль программаларны тормышка ашыру кысасында гына да торак пунктлардагы вак таш җәелгән 150 чакрым, асфальт түшәлгән 161 чакрым озынлыктагы юлны төзекләндерергә җыеналар. Министр әйтүенчә, 16 бакчачылык ширкәте, 5 балалар ял лагере, 16 авыл хуҗалыгы фермасына илтүче юлны тәртипкә китерәчәкләр.

Юлсызлыктан интегүче авыллар турында да онытмаганнар.

– Безнең 3 меңнән артык авылыбыз бар. Бүген шуларның 519ына юл юк. Төбәк дәрәҗәсендәге 13 мең чакрым озынлыктагы юлның 500 чакрымы тирәсе – грунт юллар. Мәсьәләне хәл итү өчен, мондый авылларны, үзебездә чыга торган вак таш җәеп, зур юлга тоташтырырга ниятлибез. Сүз машина хәрәкәте артык зур булмаган кечкенә авыллар турында бара. Вак таш түшәлгән юлның бәясе дә арзанрак төшә. Мондый юлның 1 чакрымы 10 миллион сумга кадәр тәшкил итсә, асфальт җәя башласаң, 1 чакрым юл хакы 17 миллион сумга кадәр җитәргә мөмкин. Былтыр республиканың Менделеевск, Әгерҗе, Мамадыш районнарында, юлларга вак таш җәеп, мондый ысулны сынап карадык инде. Яз көне сыйфаты канәгатьләндерде. Авыл эчендәге юлларга килгәндә, бүген күп кенә салаларда бу эшне үзара салым акчасына башкаралар. Халык биргән һәр 1 сум акчага дәүләт 4 сум өстәп түли. Һәркемнең яхшы юллардан йөрисе килә, әлбәттә. Әлеге мәсьәләнең ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын да аңлыйбыз, – диде Фәрит Хәнифов.

Әле шушы арада гына Мамадыш районы башлыгы Анатолий Иванов шалтыратып, сөенече белән уртаклашуын да сөйләде министр.

– Былтыр юл салган кечкенә генә Яковка авылында бүген бер генә буш җир кишәрлеге дә калмаган. Табигатьнең бик матур почмагында урнашкан әлеге саладагы җирләрне сатып алып бетергәннәр. Авылга юл салу нәтиҗәсе бу! Уйлый калсаң, элек авылларны белеп салганнар. Аларның табигате дә матур, су да басмый, инеш-елгалары, урманнары да янәшәдә. Без бетеп баручы салаларны торгызу турында Татарстанның Туризм буенча дәүләт комитеты җитәкчесе Сергей Иванов белән дә сөйләшүләр алып барабыз. Авылларны, вак таш җәеп булса да, зур юлга тоташтырырга кирәк. Мондый юлларның үз кимчелекләре бар, әлбәттә. Алар асфальт юл кебек нык түгел, саклап тотарга кирәк. Авылга 40 тонналы йөк машинасы килеп керсә, яңа юл да чыдамаячак, – ди Фәрит Хәнифов.

Хәер, М12 югары тизлекле автомобиль юлы төзелә башлаганнан бирле сала юллары җирне дер селкетеп узып китүче йөк машиналарына кадәр күрде инде. Министр әйтүенчә, федераль һәм төбәк юллары төзелеше барышында гамәлдәге 900 чакрымга якын юлны «эшкә» җиккәннәр. Зур төзелешләр беткәч, аларның барысын да рәткә китерәчәкләр, дип вәгъдә иттеләр брифингта.

Зур юллар дигәннән, агымдагы елда федераль юлларның 59 чакрымын төзекләндерәчәкләр.

– Әлеге эшләрнең күп өлеше М7 трассасының Яшел Үзән, Биектау, Менделеевск районнары һәм Чаллы шәһәренә туры килгән урыннарында башкарылачак. Зөя елгасы аша күпер салу эшләре 77 процентка үтәлде инде. Аны быелның ноябрендә үк тулысынча кулланышка тапшырырга ниятлибез, – диде «Федераль юл агентлыгының Идел-Нократ төбәге автомобиль юллары федераль идарәсе» федераль казна учреждениесе җитәкчесе Илдар Минһаҗев.

Ә Чулман елгасы аша салынучы күперне әле күптән түгел генә шәхсән Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та карап кайтты.

– Бу – бик үзенчәлекле төзелеш. Күпернең уң як яры (Алабуга районына туры килгән өлеше) бик биек. Биредә баганаларның су өстендәге биеклеге генә дә 50 метр тәшкил итә. Күпернең озынлыгы 1 чакрымнан да артып китә, – диде Илдар Минһаҗев.

«Түбән Кама районы башлыгы Рамил Муллин әлеге күпер вакытыннан алда, киләсе елда ук кулланылышка тапшырылачак дип әйтте. Бу сүзләр дөресме?» – дип тә сорады журналистлар брифингта. Җавап йөзеннән Фәрит Хәнифов та, Илдар Минһаҗев та елмаеп кына куйдылар. Эшкә күз тидерергә теләмәделәр, ахры.

Татарстан «Куркынычсыз һәм имин юллар» илкүләм проектын тормышка ашыруда да катнаша. Илкүләм проектлар, шул исәптән «Куркынычсыз һәм имин юллар» Россия Президенты Владимир Путин тәкъдиме белән 2019 елдан бирле тормышка ашырыла. Моңа кадәр, 2017–2018 елларда, илнең кайбер төбәкләрендә «Куркынычсыз һәм имин юллар» өстенлекле федераль проекты гамәлдә иде. Аның ярдәме белән республикада 1129 чакрым юл төзекләндерелгән инде. Быел проект кысасында 10 миллион сумнан күбрәк акча бүлеп бирелгән. Аерым алганда, төбәк дәрәҗәсендәге 222 чакрымга якын юлны ялт иттерәчәкләр. Мәсәлән, Азеево – Чирмешән – Шентала, Чистай – Түбән Кама, Апас – Тәтеш юлларында йөрүчеләр җиңел сулап куячак. Биредә юлларны тәртипкә китерәчәкләр. Юлчылар күперләрне дә урап узмый. Агымдагы елда республика 38 күпердә (шуларның 4ен өр-яңадан сафка бастырачаклар) төзү һәм төзекләндерү эшләре башкарылачак. Мәсәлән, Әлмәт районында Дала Зәе елгасы аша салынган күпердә ремонт эшләре төгәлләнәчәк. Чирмешәндә Зур Чирмешән елгасы аша салынган күпер дә яңа сулыш алачак.

ӘТКӘМ-ӘНКӘМНЕҢ ТЕЛЕ



Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм МИҢНЕХАНОВның Туган тел көнен һәм Габдулла Тукайның тууына 137 ел тулуны бәйрәм итү уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ

Хөрмәтле татарстанлылар!

Кадерле милләттәшләр!

Сезне Туган тел көне һәм татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның тууына 137 ел тулу уңаеннан тәбрик итәм.

Әдипнең даһиларча зур осталык белән тудырылган әдәби образлары һәркемгә таныш һәм якын. Аның әсәрләренә нечкә лирик хисләр, җәмгыятьнең иң әһәмиятле социаль темаларын күтәрү, камиллекнең югары дәрәҗәсенә җиткерелгән үткен сатира һәм юмор хас.

Яшьләргә мөрәҗәгать итеп, ул болай дип яза:

«Йөрмәсен бәгъре өзек милләт киеп кашсыз йөзек, —
Без аның бик зур фәхерле, чын брилиант кашлары!»

Бу юллардан үз халкының фикерле, уйлый белү, акыл һәм зиһен, көч һәм затлылык кебек сыйфатлары шагыйрь тарафыннан бик югары бәяләнүе ачык аңлашыла.

Аның иҗаты – милли үзенчәлекләребез кыйммәтен тану һәм Ватаныбызда яшәгән башка халыклар белән туганлык идеяләренең, гореф-гадәтләргә тугрылык һәм заманча яңа казанышларга омтылышның тыгыз үрелү үрнәге. Нәкъ менә шуңа да Туган тел бәйрәмен без Тукайның туган көнендә уздырабыз.

Тукай күтәргән мәсьәләләр күпмилләтле Татарстанда игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елының рухи хәзинәләребезне саклау һәм үстерү, борынгы традицияләребезне тергезү, шулай ук Россия халыклары мәдәни мирасын тагын да баету кебек максатларына аваздаш.

Бәйрәм чаралары яңа иҗади казанышларга бәрәкәтле этәргеч бирсен, тарихи тамырларыбыз белән кызыксынуны көчәйтсен һәм һәркемгә якты тәэсирләр бүләк итсен!

Сезгә чын күңелдән нык сәламәтлек, бәхет һәм иминлек телим.

Җиңү тасмалары

Татарстан «Георгий тасмасы» халыкара акциясенә кушылды. Чара Казанның Камал театры алдындагы мәйданчыкта башланып китте. Яшьләр эшләре министрлыгы хәбәренә караганда, республикада яшәүчеләргә 200 мең Георгий тасмасын тапшыру күздә тотыла.

«Патриот» республика спорт-ватанпәрвәрлек һәм яшьләрне хәрби чакырылышка кадәр әзерләү буенча республика үзәге директоры Дмитрий Литвинов әйтүенчә, Бөек Ватан сугышы чорында фашизмга каршы көрәштә катнашкан ата-бабаларыбызның истәлеген хөрмәтләү билгесе бу. Акция махсус хәрби операция барган вакытта аеруча зур әһәмияткә ия.

Рекорд кабатланган

Республикада һава торышы рекорд куюны дәвам итә. 24 апрельдә һава +22,8 градуска кадәр җылынган. Апрель аенда мондый югары температура соңгы тапкыр 50 ел элегрәк – 1975 елда булган, дип хәбәр итә Татарстан Гидрометеоүзәге.

Атна ахырына исә +26 градуска кадәр җылыта. 28 һәм 29 апрельдә республика бик җылы һава агымнары чолганышында калачак.

Сәламәтлек

«Омикрон» туганы

АВЫРУЧЫЛАР МАЙ АЕНДА АРТАЧАК, ДИП ФАРАЗЛАНА

Коронавирус турында оныттым дигәндә генә, аның яңа штаммнары пәйда була. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы пандемия тәмамлану турында игълан итмәде, чир йоктыру очраклары көн саен барлык илләрдә дә диярлек теркәлә.

Менә шушы арада «арктур» дигәнен еш телгә ала башладылар. Алдан ук кисәтик: йогышлылыгы ягыннан аңа кадәр булган «туганнар»ыннан зәһәррәк, ди. Алдан ук тынычландырыйк: хәзер чир җиңелрәк уза.

Роспотребнадзор башлыгы Анна Попова хәбәр иткәнчә, Россиядә «арктур»ны йоктырып авыручылар саны май ахырына артырга мөмкин. Аның сүзләренчә, штамм башкаларына караганда күпкә йогышлырак, әмма ул сирәк очракта авыр уза, нигездә кеше аны ОРВИ буларак кичерә икән. Попова сүзләре белән әйткәндә, «арктур»ның контагиозлыгы (таралучанлыгы, йогышлылыгы) элегрәк формалашкан иммунитетны да урап узарга мөмкинлек бирә. Тик шулай да илдә яңа санитар-эпидемиологик чикләү чаралары кертергә уйламыйлар, сәламәтлек саклау тармагының мондый хәлләргә әзер булуына ышаналар.

Әлегә илдә «арктур» белән чирләүнең дүрт очрагы теркәлгән. Сүз уңаеннан, «арктур» дөньяның 29 илендә ачыкланган инде.

Терапевт Олег Абакумов аңлатканча, «арктур»ның төп билгесе – конъюнктивит. «Аны аллергиядән аеру бик җайлы. Мәсәлән, аллергия вакытында күз кабаклары шешә, төчкерү бар, борыннан ага, тамак авыртмый, күздән чыккан сыеклык та үтәкүренмәле була. «Арктур»ның башка билгеләре үзгәрешсез: тамак авырту, какырыксыз ютәл, борын тыгылу. Бу юлы тәм һәм ис югалмаячак», – ди табиб.

Авыру билгеләре күзәтелсә, билгеле, иң элек табиб ярдәме кирәк. Шулай да, Олег Абакумов аңлатканча, «арктур» үзен сиздерә башласа, организмны кайгырта башлау зыян итмәс. «Ингаляция ясарга, Д витамины эчәргә, тамакны чайкарга, табиб күрсәтмәсе булса, канны сыекландыргыч дарулар эчәргә кирәк. Бу бигрәк тә өлкәннәргә һәм диабет чиреннән интеккәннәргә кагыла. Дәваланганда даимилек кирәк! Башкача нәтиҗә булмаячак», – дип кисәтә терапевт.

Моннан тыш, чирләгәндә нәрсә эшләргә ярамаганын да искәртә ул. «Бала көткәндә, бөерләр авыртса, аллергия интектерсә, чир 14 көннән дә озаграк дәвам итсә, вируска каршы дарулар эчәргә ярамый. Әгәр дә организм аларга кытлык кичерми икән, кирәксә-кирәкмәсә, магний, калий эчмәскә. Шулай ук белер-белмәс аспирин, кардиомагнил эчәргә ярамый», – дип кисәтә белгеч.

САН

«Стопкоронавирус.рф» сайты мәгълүматларына күз салсаң, илдә узган тәүлектә коронавирусны 5093 кеше йоктырган. Шуларның 1339ын хастаханәгә озатканнар. 7397 кеше сәламәтләнгән. Аерым алганда, Татарстанда 31 очрак ачыкланган. 15 кеше хастаханәдә дәвалана. Бер тәүлек эчендә 97 кеше сәламәтләнеп чыккан. Үлем очрагы юк.

Сүзгә-сүз

Никита ЧАПЛИН, Россия Дәүләт Думасының Бюджет һәм салымнар буенча комитет әгъзасы:

Россиядән киткән гражданнарга салымны арттыру Россия икътисадын тотрыкландыру өчен кирәк. Кайберәүләр Бали яки Мальдив утрауларында яшәп ята, ә керемне Россия компанияләреннән ала. Дөрес, һәркемнең яшәү урынын сайларга хокукы бар, әмма бу очракта үз иле бернинди дә зыян күрергә тиеш түгел. Зур күләмдә салым түлиселәре килмәсә, Россиядән китмәсеннәр.

(«Российская газета»дан)

РОССИЯЛЕЛӘРНЕҢ МАТДИ ХӘЛЕ

Webbankir онлайн хезмәте илдә яшәүчеләрнең акчасын «санаган». Алар кешеләрдән: «Матди хәлегезне нинди дип бәялисез?» – дип сорашкан. Өчтән бере «яхшы», хәтта «бик яхшы» дигән.

71,3%	азык-төлеккә акчаны кысыбрак тота
35,4%	кибеттәге барлык товарны сатып алырлык хәлдә түгел
28,7%	азык-төлеккә киткән акчаны санамый
28,2%	ошаган бар нәрсәне дә сатып ала, әмма акцияләр булганда гына

Реклама 16+

Сөенечле хәбәр!

2023 елның 10–27 апрель көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 жомга саны

Ташламалы бәя 444 сум 54 тиен

гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга

Ташламалы бәя 1051 сум 80 тиен

гадәти бәясе – ~~1227 сум 30 тиен~~



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КЕМ БЕЛӘН СИН, УРТА АЗИЯ?

Соңгы көннәрдә АКШ һәм аның көнбатыштагы аркадашлары Россиягә товар экспортлауны бөтенләй туктату идеясе белән янып алдылар. Ләкин фикер Зур җиделек илләрендә тулысынча ук яклау тапмады шикелле. Инде кертелгән санкцияләрне җиренә җиткерү максатына ирешү көн тәртибенә калкурак итеп куелды. Тарихта күрелмәгән сандагы санкцияләр яңгыры астында калса да, Россия икътисады аларны әлегә кадәр чагыштырмача җиңел кичерә. Вашингтон бу юлы глобаль рәвештә бердәм фронт оештыра алмады. Дус илләр Россия белән хезмәттәшлекне туктатмадылар. Хәтта Якын Көнчыгышның нефть державалары да Зур җиделек башлаган икътисад сугышыннан канәгать түгел. Дөрес, алар барысы да үз мәнфәгатьләрен кайгырта, беркем дә Мәскәүгә мәхәббәт белән янмый.

Россия белән кендекләре тыгыз бәйләнгән илләр бар. Элек бер түбә астында яшәгән Урта Азия илләре, мәсәлән, Көнбатыш санкцияләрен тулысынча үтәсәләр, үзләре кыен хәлдә кала. Менә шул илләр, нигездә, Мәскәүгә җилкә куйдылар да инде: параллель импорт шулар аша үткәрелә, сәнәгать предприятиеләре арасында өзелгән җепләр яңартыла. Ул илләр өчен Россиягә кертелгән санкцияләр әлегә кадәр бонуслар гына бирде: Россия бизнесының байтак өлеше шул төбәктә теркәлде, банкларына валюта коелды һәм башкалар.

Вашингтон һәм Брюссель Россияне Урта Азия белән бәйләгән «кан тамырлары»н өзәргә ниятлиләр. Үткән айларда да океан арты сәясәтчеләре ул төбәкләрдә булып киткәннәр иде. Бу дүшәмбедә АКШ финанс министрының террорны финанслауга һәм финанс җинаятьләренә каршы көрәш буенча урынбасары Элизабет Розенберг белән Европа Союзының санкцияләр буенча махсус илчесе Дэвид О'Салливан Казахстанга килделәр. Көнбатышлыларның тәкъдиме шундый: я Россиягә санкцияләрне әйләнеп үтүгә булышудан туктыйсыз, я без сезгә Көнбатыш базарларын ябабыз. Розенберг шундый ук тәкъдим белән 26–28 апрельдә Кыргызстанда да булачак. О'Салливан Бишкәктә булды инде. Европа Советының товар агымнарын контрольгә алачагын әйтеп китте.

Үзбәкстан, Казахстан, Кыргызстан кебек илләр Россия белән генә түгел, Көнбатыш һәм Кытай белән дә тыгыз бәйләнгән шул хәзер. Әмма Мәскәү белән араны өзү дә аларга кыйммәткә төшәчәк. Алар болай да Көнбатышка ярарга тырышалар инде: Россия тәкъдим иткән проектларның байтагы кире кагыла, товар агымнарын контрольгә алырга тырышалар. Казахстан үз нефтен Көнбатышка Баку аша озата башлады, Россия аша үтүче маршруттан баш тартты. Хәер, бу соңгысында Мәскәү үзе гаепле. Россияле аналитиклар, Урта Азиягә безнең белән араны өзү зыянлы, шуңа күрә көнбатышлылар зур уңышка ирешмәс, дип өметләнәләр. Ләкин басым көчәя һәм тартышның кем файдасына тәгәлләнүен киләчәктә күрербез, мөгаен.

Россиядә

КИТКӘНСЕҢ ИКӘН, КҮБРӘК ТҮЛӘ

Соңгы көннәрдә телеграм-каналларда күренгән хәбәр дөрес булып чыкты. Чынлап та, Дәүләт Думасы илне ташлап киткән мөһаҗирләрдән физик затларның кеременә салымны зуррак ставка белән түләтү турында канун кабул итәргә җыена. Бу юлы инициатива авторы – кычытмаган җирне каршырга яратучы чиктән тыш актив депутатлар түгел, ә Финанс министрлыгы. Димәк, канун кабул ителәчәк. Алдагы санга язма әзерләгәндә әйткән идем: салымнарны арттыру бюджет кытлыгыннан котылуның бер юлы итеп сайланачак. Дүшәмбе көнне Хөкүмәт Думага салым законнарына үзгәрешләр турында зур исемлектән торган тәкъдимнәр кертте. Мәгълүмат кыры релокантлар – чит илгә китеп, Россия предприятиеләренә эшләүчеләр – салымына үзгәрешләр турындагысына зур игътибар күрсәтте. Инициатива болайрак шәрехләнә: Россия компанияләре чит илгә киткән хезмәткәрләрдән физик затларның кеременә салымны башта 13–15 процент күләмендә тоталар, салым резидентлыгы статусы югалгач, 30 процентка җиткерәләр. Хәзерге кагыйдәләр буенча, кеше календарь елы дәвамында туган илендә 183 көннән азрак яшәсә, салым резиденты статусын югалта.

Башта бик дәһшәтле күренсә дә, яңа закон либераль булырга охшаган. Иң мөһиме: мөһаҗирләр бернидә дә гаепләнми. Салымыңны түлә дә тыныч йокла. Моңа кадәр релокантларны илгә кайтарырга тырышып карадылар, аларга карата каты санкцияләр кертү фикерләре бер генә тапкыр яңгырамады. Әмма эше һәм ашы булган мөһаҗирләр туган якка юл тотарга ашыкмый. Россия компанияләренә эшләгән хәлдә читтә яшәүне кулайрак күрә. Аларга карата җәза операцияләре үткәрә башласаң, икътисад иң кирәкле кадрларны югалта. Путин үзенең Юлламасында эмигрантларга җылы мөнәсәбәттә калачакларын әйткәч, җепшеклек күзәтелде.

Салымдагы үзгәрешләр мөһаҗир өчен артык зур йөккә әйләнмәс кебек. Бердән, 30 процентлык ставка барлык релокантларга кагылмый. Аны компания белән гражданлык-хокукый килешүе нигезендә хезмәттәшлек итүче фрилансерлар, блогерлар гына түләячәк. Хезмәт килешүе нигезендә эшләүчеләр өчен элекке ставка кала. Бер нечкәлек бар барын: закон проектына үзгәрешләр кертеләчәк. Канунга әйләнгәндә, аның рәвеше нинди буласын хөкүмәттә дә өзеп әйтмиләр.

Яңа салым ставкасы мөһаҗир интернетның Россия сегментыннан файдаланганда гына гамәлгә керә. Хезмәт хакын Россия банкы аша алса гына, салым түләтеп була. Сер түгел: читкә китүнең төп сәбәпләренең берсе чит ил банкында хисап ачу иде. Хисабың Россия банкында булса, чит илдә акчаңны файдалану – болай да кыен эш бит. Канун кабул ителсә дә, зур ставкадан качуның юллары җитәрлек, ди белгечләр. Шәхси эшмәкәргә әйләнеп була, үзмәшгуль буларак та теркәлә аласың. Аннан соң ставканы компания җитәкчесе билгели, теләсә, элекке ставканы да калдыра ала. Артык кырыс канун кабул итсәң, кадрларсыз калуың да ихтимал, моны хөкүмәттә аңлыйлар.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

УРТАК НИЯТ

Казан – Ташкент арасы тагын да якынайды. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендәге республика делегациясенең Үзбәкстанга эш сәфәре барышында Җизак шәһәрендә уртак проект – яңа технопарк эшли башлады. Республиканың 50ләп компаниясе вәкилләре халыкара күргәзмәдә катнашты. Рәис берничә очрашу үткәрде.

tatarstan.ru

Эш сәфәренең икенче көнендә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов «Иннопром. Үзәк Азия» халыкара сәнәгать күргәзмәсендә катнашты. Әлеге чарага республикадан «Алабуга» махсус икътисадый зонасы, «Химград», «Таткабель», «Казан вертолет заводы», «Казанькомпрессормаш» кебек 50гә якын компания вәкилләре дә барды. Күргәзмә кысасында алар үз предприятиеләрен тәкъдим итте. Республика стендын Рөстәм Миңнеханов Сорхандәрья һәм Ташкент өлкәләре хакимнәре белән бергә карады.

Татарстан Рәисе «Иннопром»ның пленар утырышында да катнашты. Халыкара сәнәгать күргәзмәсе 700дән артык компания вәкилләрен бер мәйданга җыйган. Катнашучылар арасында хакимият органнары вәкилләре, бизнесменнар, инженерлар, IT белгечләр бар иде. «Иннопром»ны Россия Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән Үзбәкстанның Инвестицияләр һәм тышкы сәүдә министрлыгы оештырган. Ул өч көнгә исәпләнгән. Күргәзмәнең пленар утырышында Россия Хөкүмәте рәисе урынбасары, сәнәгать һәм сәүдә министры Денис Мантуров, Үзбәкстан Премьер-министры урынбасары, инвестицияләр һәм тышкы сәүдә министры Җамшид Ходжаев, Үзбәкстанның энергетика министры Журабек Мирзамәхмүтов чыгыш ясады.

– Соңгы арада без Үзбәкстандагы партнерларыбыз белән тыгыз элемтәдә торабыз. Казан һәм Ташкент – тугандаш шәһәрләр. Иң уңышлы уртак проектларның берсе – «Чирчик» химия-индустриаль технопаркы, – дип белдерде Рөстәм Миңнеханов Үзбәкстанның Ташкент өлкәсе хакиме Зоир Мирзаев белән очрашканда. Алар хезмәттәшлекне үстерү юллары турында фикер алышты.

Узган ел Татарстан белән Үзбәкстан арасында товар әйләнеше 290 миллион доллардан артып киткән. Үсеш 50 процент тәшкил иткән.

Ватан кадере

Дәүсоветта

«Без – Россия гражданнары» дип аталган парламент дәресләре кысасында узган иҗади бәйгегә тугыз телдә (!) эшләр кабул ителгән. Укучылар Ватан темасына инша язган, рәсем ясаган, видео төшергән. Җиңүчеләрне кичә Дәүләт Советында бүләкләделәр.

Быел республикада парламент дәресләре унбишенче мәртәбә үтте. Ел саен әлеге проект кысасында укучылар иҗади бәйгедә көч сынаша. Быел бәйгенең республика этабында 455 бала катнашкан.

– Дөнья үзгәреп тора. Яңа законнар кабул ителә. Балалар шуның белән бик кызыксына. Белемнәре дә арта. Бер елны дәрескә Казаннан белгечләр килгән иде. Балалар шундый канәгать калды. Тагын килсеннәр, диләр. Бәйгегә «Тамырлар» дип аталган туган якны өйрәнү музее эшчәнлеге турында видео тәкъдим иттек, – ди Чистай районының Йолдыз мәктәбе җәмгыять белеме укытучысы Әлмира Шәрифуллина.

– Әлеге чара елдан-ел кызыклырак үтә. Укучыларны әзерләгән өчен, беренче чиратта, җәмгыять белеме укытучыларына рәхмәт. Дәресләрдә югары сыйныф укучылары әллә нинди катлаулы сораулар бирә. Кайчак югалып та каласың. Әлеге дәресләрдә катнашып, сез, укучылар, бик күп белемнәр аласыз, – диде җиңүчеләрне тәбрикләү тантанасында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Юрий Камалтынов.

Чара яшь барабанчыларның барабан кагуыннан башланган иде. Юрий Камалтынов аның тавышыннан үзе укыган еллардагы популяр булган җырның көен шәйләп алды. «Кызганыч, замана балалары бу җырларның берсен дә белми… Шулай ук яшь партизаннар Леня Голиков, Марат Казей, Володя Дубининны да белми. «Парламент дәресләре» патриотик тәрбияне кире кайтарырга ярдәм итсен, балалар һәр дәрестән Ватанга хөрмәт, мәхәббәт хисен сеңдерсен иде», – диде Юрий Камалтынов.

Сәрия МИФТАХОВА

БӘЯНЕ ХАЛЫК БИРӘ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит МӨХӘММӘТШИНның Россия парламентаризмы көне уңаеннан КОТЛАВЫ

Хөрмәтле коллегалар – барлык дәрәҗәдәге вәкиллекле хакимият органнары депутатлары! Кадерле татарстанлылар! Сезне ихлас күңелдән Россия парламентаризмы көне белән котлыйм.

2023 елда илебезнең хәзерге парламент системасы юбилеен билгеләп үтә. Моннан өч дистә ел элек, 1993 елның 12 декабрендә, беренче мәртәбә ике палаталы парламент – Россия Федерациясе Федераль Собраниесе сайланды. Шушы еллар дәвамында законнар чыгару эшендә һәм парламент эшчәнлегендә гаять бай тәҗрибә тупланды, заманча дәүләти-сәяси системаның хокукый нигезе булдырылды, ил яшәешенең бөтен өлкәләренә – граждан хокукына, мәгарифкә, сәламәтлек саклауга, экологиягә, төбәк, торак, гаилә һәм яшьләр сәясәтенә кагылышлы һәм көн кадагындагы мәсьәләләргә җавап бирергә тиешле йөзләрчә законнар эшләнде. Илебез мәнфәгатьләрен дөньякүләм дәрәҗәдә яклауда һәм парламентара хезмәттәшлектә Россия закон чыгаручыларының абруе артты. 2020 елда парламент, халкыбыз тарафыннан хупланганнан соң, Россия Конституциясенә төзәтмәләрне раслады, алар дәүләт суверенитетын сизелерлек ныгытты, закон чыгару хакимият органнары, регионнар һәм муниципалитетларның заман таләпләренә туры килә торган хокукый базаны булдыру эшендә җаваплылыгын арттырды.

Бүгенге тормыш, нинди партиядән булуга һәм сәяси фикерләү төрлелегенә карамастан, барлык дәрәҗәдәге (федераль, республика, муниципаль) депутатлардан иҗтимагый процессларда даими һәм актив катнашуны, шәхси җаваплылыкны һәм эшкә конструктив карашны таләп итә. Көн тәртибендә – илебез һәм аның халкы мәнфәгатьләрендә комплекслы системалы закон чыгару эшчәнлеге; һәр закон чыгару инициативасын тирәнтен анализлау һәм, иң беренче чиратта Төп законны үтәү һәм гражданнарның конституциячел хокукларын тәэмин итү өлешендә, аны гамәлгә ашыру, ихтимал булган зыяннарны бетерү механизмын һәрьяклап эшләү. Һәр халык вәкиленең бурычы – үзенең бөтен эше белән аңа күрсәтелгән ышанычны аклау, чөнки безнең эшчәнлеккә бәяне сайлаучы, илебезнең күпмилләтле халкы бирә. Шуңа күрә дә һәрвакыт «тормыш дулкыны»нда булу, җәмәгать фикеренә таяну, кешеләрнең кәефен сизү һәм аларның таләпләрен тыңлау, турыдан-туры гражданнарның наказлары һәм мөрәҗәгатьләре белән эшләү бик тә мөһим.

Хөрмәтле татарстанлылар! Шушы истәлекле көндә Сезгә тынычлык һәм иминлек, нык сәламәтлек һәм Татарстан Республикасы, көчле Россия Федерациясе бөеклеге хакына уңышлар телим! Ышанам ки, без бөтен куелган максатларга ирешәчәкбез!

БЕЗ САЙЛАГАН ЮЛ

Татарстан Республикасы юстиция министры Рөстәм ЗАҺИДУЛЛИНның Нотариат көне белән КОТЛАВЫ

Хөрмәтле нотариуслар һәм нотариаль палаталар хезмәткәрләре! Нотариат көне уңаеннан чын күңелдән котлауларны кабул итегез!

30 ел эчендә Татарстан Республикасы нотариаты зур, җитди үсеш юлын үтте, гражданнарга һәм юридик затларга квалификацияле юридик ярдәм күрсәтүнең иҗтимагый-хокукый системасының төп институтларының берсенә әверелде.

Нотариат үсеше дәвам итә. Республикада хокукый якланганлыкны тәэмин итү һәм хокукый культура дәрәҗәсен күтәрү өчен нотариуслар эшенең югары әһәмияте үзгәрешсез кала.

Нотариусларның югары дәрәҗәдәге һөнәри компетентлыгы, аларның принципиальлеге һәм сайлаган юлларына тугрылыгы җәмгыятьтә тотрыклылыкны саклауның мөһим шарты булып тора.

Сезгә нык сәламәтлек, бәхет, иминлек, җаваплы эшегездә уңышлар телим! Бәйрәмегез белән котлыйм!

«БЕЗНЕҢ КҮҢЕЛ МОНДА БЕРЕККӘН»

НУРУЛЛА УЛЬДАНОВ 47 НЧЕ УРАГЫНА ҖЫЕНА

Нурулла Ульданов – Балтач районының данлыклы комбайнчысы, механизаторы. Токарь, тимерче дә әле ул. Бу көннәрдә аңа «Татарстанның атказанган механизаторы» дигән мактаулы исем бирү турында республика Рәисенең карары имзаланды. Без Арборга барган көн аның туган көне – 60 яшьлек юбилее да булып чыкты. Мактаулы исеме белән дә иң беренче булып без котладык.

Ялан кыр кадәр иркен паркта трактор ремонтлаучы Нуруллага иң беренче сүзебез дә: «Юбилей көнне кем эшли ди инде?!» – булды.

– Әй, без шулай күнеккән инде, – диде ул, котлауларыбызга ихлас сөенеп. – Минем дә өйдәгеләр әзерләнә. Балалар, оныклар кайтты, туганнар җыела. 1976 елда, алтынчы сыйныфны бетергән елны шушы паркка комбайнчы ярдәмчесе булып килгән идем, шуннан бирле монда инде мин. Тугызынчыны тәмамлаган елны комбайнда үзем мөстәкыйль эшләдем. 1980 елдан – «ДТ» тракторында. Дөрес, хәзер инде «ДТ»ларга элекке кебек нагрузка юк. Мин эшли башлаган елларда колхозларның да, авылларның да төп эш көче иде алар. Елның 365 көнендә дә эш бетми иде. Шәп эшли иде! Аның эшен әле дә басуда бик яраталар.

:: Күпләр бит бу тракторларны эшләр өчен авыр, ди…

– Сүз дә юк, авырлыгы бар. Селкетү-чайкалдыруына түзәр иден, тавышы бик яман. Элек алты сәгать бер якка барып, анда ике сәгать эшләп, тагын алты сәгать кайта идек. Көн-төн шул тавышта ничекләр эшләдек икән дип аптырыйм. Хәзер азга гына утырасың, анда да тавышына түзә торган түгел. Минем берүземә ике «ДТ» бар. Менә монысы 1991 елгы, тегесе бер елга яшьрәк. Монысы белән ферма тирәсендә эш чыгып тора, аннан тыш кыш көне бөтен авыл урамнарын, тыкрыкларын кардан чистартам. Быел тегесен дә бик әйбәтләп ремонтлап куйган идем, утыручы гына табылмады, техника җитешмәгәндә ике көнгә генә басуга чыгып эшләп кердем. Тавышына түзә алмыйча, колакка мамык тыгып эшләдем. Яшь тә бара шул инде, сәламәтлек тә чамалы. Әле табиблар бөтенләй мондый эшләрдә эшләмәскә куша… Тик шулкадәр якын бит бу техникалар. Уйласаң, бөтен гомер шуларда үткән.

:: Тракторларыгыз иске булса да, комбайныгыз өр-яңа икән… Танышларыгыз: «Яңа комбайнга утыргач, Нурулланы кояш та ашамый башлады, башка чакта кырда эшләгәндә каралып бетә иде, хәзер йөзләре ап-ак кала», – дип шаярта…

– Әй, ул яңа комбайнда эшләүнең рәхәтлекләре! Эссе дә түгел, салкын да… Тузан да юк, тавыш та… Эсседә шоферлар минем кабинага суынырга керә хәзер. СК-5 белән эшли башлаган идем, аннан соң ике «Нива»да 28 ел эшләдем. «Акрос»ка җитми берсе дә. Киндеридән кадәр үзем барып алып кайттым мин аны. Үз ходы белән. Хәзер хуҗалыкта ике комбайн – ике комбайнчы калдык, 20–25әр комбайн булган, басуда 15–20ләбе эшләгән еллар бар иде. Җир шул ук, шуңа күрә безгә нагрузка шактый.

:: Сезне ярдәмчесез генә эшли, диләр…

– Шулай эшләргә яратам шул. Соңгы елларда гел берүзем. Баштарак ярдәмчеләр алдым. Төрле кеше белән эшләсәм дә, штурвалны Ралиф дигән егеткә һәм кызым Гөлнарага гына бирдем. Аларга ышанганмындыр инде.

Гаилә дигәннән, миңа бит, әйбәт хезмәт иткәч, хәләл җефетемне армиядән үк биреп кайтардылар. Аның белән поездда, плацкарт вагонда таныштык. Таныштык дип, ул чакта бит, дуракка карта уйнау модада иде. Җыйнаулашып карта уйнап кайтабыз. Арабызда яшь кенә кыз бала да бар. Апаларына кунакка барышы. Русча аралашсак та, дурак калган өчен җәза үтәргә дигәч, әлеге кыз саф татарча «Кыр казлары» дигән җырны җырламасынмы?! Сөйләшеп киттек, таныштык. «Әйдә, безгә кунакка кайтабыз», – дидем дә алып кайттым. Әле бит авылда өч ел йөргән кызым да бар иде… Без кайтканда, әни күршеләрдә иде. Авылдашлар: «Улың бер кыз белән кайтты», – дигәч, әни: «Безнеке дә марҗага өйләнгәндер инде», – дип, өйгә дә кайтмый торды әле (аңа кадәр армиядән берәү шулай өйләнеп кайткан була. – **Г.Х.**). Икебез бергә барып, Гөлҗамал берничә сүз татарча әйткәч кенә, әнинең эченә җылы керде. Шөкер, 39 елга якын аңлашып, матур яшәдек, өч бала үстердек. Ул да эштән курка белмәде, авылга кайтуының бишенче көнендә фермага эшкә керде. Бергә-бергә тырышып, йорт-җир өлгерттек, башка чыктык, эшләп яшәдек.

:: Әле бит олыгая төшкәч кенә бер ятим баланы да үз канатыгыз астына алгансыз…

– Хатыным, РИУда белем алганда, шактый авыр хәлдә калган бер әби белән танышкан иде. Кызы төрмәдә, балаларының икесе әтисендә, ун айлыгын үзе карый. Сәламәтлегем дә шәптән түгел, бу баланы ничекләр үстерермен дип борчылган. Хатыным кайтты да шушы хәлне сөйләде. «Балалар үсеп бетте, әллә үзебезгә алабызмы?» – диде. Мин каршы килмәдем. Дөрес, ун айлык баланы күргәч, башта бераз курыкты инде. Хәзер кызыбызга – алты яшь. Бик тә яратабыз үзен. Догалар белә, әнисе белән намазлар укый. Бик тәртипле, искиткеч сөйкемле бала. Ничекләр алдык, дибез. Минем юбилейга да бүләк әзерләгән әле, күрсәтмәде, кич кенә бирәм, диде. Әнисе – татар, әтисе – рус милләтеннән. Исемен дә, фамилиясен дә үзгәртмәдек, әтисе баладан баш тартмады. Әбисе вафат инде. Әтисе белән елга бер очраштырабыз. Бар курыкканыбыз: бер көн килеп, әтисе алып китәм дисә, нишләрбез, дибез…

:: Авылда калганга үкенгәнегез булдымы?

– Бер тапкыр да! Күпме кыстасалар да, бер тапкыр да шифаханәгә дә барганым юк минем. Шәһәрдә яшәүче улыма да: «Нәрсә таптыгыз анда?» – дим. Әллә нигә бер барам, бер кичтән артык тора алмыйм, тизрәк авылга кайтам. Безнең күңел монда берекән инде.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

ӨСТӘЛЕМДӘ – АХИРӘТЕМ

«СӨЕМБИКӘ» ЖУРНАЛЫ 110 ЕЛЛЫГЫН БИЛГЕЛӘП УЗДЫ

Туташларның да, ханымнарның да, ак яулыклы әбекәйләрнең дә ышанычлы ахирәте ул. Быел 110 яшен тутырган «Сөембикә» журналын, яратып, әнә шулай атыйлар. Хатын-кызлар өчен нәшер ителүче бердәнбер әдәби-нәфис басма «Сәйдәш» мәдәният үзәгендә күркәм юбилеен билгеләп узды.

«Сөембикә» журналының 110 еллык юбилей кичәсендә III Бөтендөнья татар хатын-кызлары съезды делегатлары да катнашты. Гомумән, бу чара съезд узасы көннәргә туры китереп оештырылган иде. Юкка гына түгел, билгеле: беренчедән, журнал татар хатын-кызлары турында сөйли һәм алар өчен нәшер ителә, икенчедән, «Ак калфак» татар хатын-кызлары берләшмәсе дә нәкъ менә «Сөембикә» канаты астында оеша. Хатын-кыз хокукларын яклау, иҗтимагый эшләр белән бәйле чорда – 1992 елда – журналның элеккеге баш мөхәррире Роза Туфитуллова нигез сала аңа.

– «Сөембикә» журналын «Ак калфак» оешмасының бишеге дип тә әйтергә була. Мин үзем редакциядә 1993 елда эшли башладым. Бу – оешма эшләп китүнең беренче еллары. Шуңа күрә чишмә башында торучы ханымнарның күбесе һаман да күз алдымда: ул елларда журналда эшләүче журналистлар Филисә Хәкимова һәм Роза Камалетдинова, рәссам Бакый Урманченың җәмәгате Флора Әхмәтова-Урманче, Сәйдә абыстай Аппакова, Дания Нуруллина, Гөлзадә Сафиуллина… «Ак калфак»ның «Сөембикә» журналы белән берлектә уздырылган «Гыйффәт туташ», «Киленбикә» кебек халыкара бәйге-тамашаларын оештыруда да ул елларда эшләүче редакция коллективының өлеше зур, – диде бу җәһәттән журналның баш мөхәррире Лариса Маликова.

Шулай итеп, төрле яшьтәге туташ һәм ханымнар белән бергә бар мәгънәдә дә гүзәл тамаша карап кайттык без.

«Әни журналы»

«Сөембикә» – татар матбугатында иң озын гомерле басма. «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев сүзләре белән әйтсәк, 110 ел гомер – бик зур җаваплылык ул.

– Бай мирасны саклау, шул ук вакытта заман белән бергә атлау, хаклыкчанлыкны да югалтмау – зур казаныш, – диде ул, журнал коллективын бәйрәмнәре белән котлап. – Миннән журналның тиражын сорыйлар. Әмма бу очракта эш тиражда түгел. Мисал өчен, язылу чоры башлануга, әни «Сөембикә»гә язылырга куша. Журнал авылга килүгә, аны бөтен урамнары белән укыйлар. Чиратлашып. Шуңа күрә «Сөембикә»не укучылар рәсми саннардан күпкә күбрәк ул.

Юбилей ияләрен котларга килгән рәсми затларның күбесе «Сөембикә»не «әни журналы» дип атады. Аларның котлау сүзләре дә җылы хатирәләргә, кызыклы вакыйгаларга төрелгән иде. Татарстан Дәүләт Советы депутаты Римма Ратникованың 92 яшьлек әнисе күзләренә операция ясаткан көнне дә журналны укымыйча түзә алмаган.

– Операция булган көнне үк, кызым, миңа укырга ярыймы әле, дип шалтыратты. Баксаң, әнигә «Сөембикә»нең яңа саны килгән. Шуны кулына алып укыймыча түзә алмый икән. Журналның шундый тугры укучылары күп. Гомумән, «Сөембикә» – зур дәрәҗәдә чыга торган басмаларның иң озын гомерлесе, – диде ул. Сәхнәдән Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның котлау сүзләрен дә җиткерде.

Татарстан Рәисе каршындагы Мәдәниятне үстерү фонды башкарма директоры Нурия Һашимова да туган йортында әлеге журналның урыны һәрвакыт түрдән булуын әйтте, «Сөембикә»нең тәрбияви ролен ассызыклады.

Заман хатын-кызларының көзгесе

«Сөембикә»нең бүгенге авторлары – хатын-кызлар. Гомумән, татар хатын-кызларының җәмгыятьтәге урыны һәм роле турындагы журнал тарихында хатын-кыз журналистларның өстенлек итүе – табигый нәрсә. Ләкин басмага ир-егетләрнең дә кулы тигән. Бәйрәм концерты башланыр алдыннан 22 ел буе гүзәл затлардан торган коллективта эшләп, хатын-кыз күңеленең бар нечкәлекләрен аңлап иҗат иткән Марат Әмирханов белән әңгәмә кордык. Чәчкәләр арасында эшләүнең рәхәт һәм бераз гына катлаулы якларын сөйләде ул.

– «Сөембикә» журналының башында ир-атлар торган. Аның беренче нашире һәм мөхәррире, журналга юл ярган кеше дә – Ягъкуб Хәлили. Аннан тыш та басмада күренекле ир-ат язучыларның эшләве билгеле. Бүгенге «Сөембикә»нең атасы Һади Такташ турында да әйтми калып булмый. Ул чакта «Азат хатын» атамасы белән чыккан журналга юл күрсәтә, баш мөхәррир Гөлчирә Гафуровага («Азат хатын»ның 1931–1937 еллардагы баш мөхәррире. – **Авт.**) журналистика серләрен өйрәтә шагыйрь. Үзем исә журналда 22 ел эшләдем. Бу еллар арасында хатын-кызлар белән эшләүнең шактый гына үзенчәлекләрен отып алдым. Аларга хәерхаһлы булып торсаң, барысына да тигез карасаң, дусларына әйләнәсең. Шунда берсен булса да аерасың икән, беттең диган сүз, син – дошман. Хатын-кызда кырык чыра бар, шуның иң яхшысын сайлап ала алсаң, уңыш елмая инде. Гүзәл затлар белән эшләү бик рәхәт, ир-атлардан аермалы буларак, ышанычлы алар. 22 ел дәвамында 4 баш мөхәррир белән эшләргә туры килде, әмма нинди генә авыр чаклар булса да, берсе белән дә сүзгә килмәдек, – дип сөйләде Марат ага.

«Сөембикә» хатын-кызлар турында яза. Марат Әмирханов әйтмешли, нәзберек тә, нәфис тә, пыяла кебек уалучан да, бераз гына үпкәләүчән һәм хәйләкәр затлар турында. Шуңа да аларга аеруча игътибарлы булырга, күңелләренә сак кагылырга кирәк, ди ул.

Марат агадан журналның бүгенге хәленә нинди бәя бирүен дә сорадык.

– Бүген инде әүвәлге «Азат хатын» да, без эшләгән «Сөембикә» дә юк. Хәзер ул – «гламурный» журнал. Аны ачып карап чыгу гына да эстетик ләззәт бирә. Журнал хәзерге заманга туры килә. Яңа санны гына алыйк. Ул – чын Европа стилендә ясалган басма. Эшләнеше бик уйланылган, язмаларын укый башлаганчы ук яхшы тәэсир калдыра, – диде ул.

Журнал үсеш-үзгәрештә. Моны аның бүгенге баш мөхәррире дә искәртте.

– Замана шуны таләп итә. Әмма журнал традицион кыйммәтләр турында да онытмый. Хәзер бит әледән-әле нейрочелтәр турында сөйләшәләр. Имеш, журналистларны бөтенләй алыштырачак. Миңа калса, мондый эчтәлекле, затлы-зәвыклы журналны күзләре янып торган кешеләр генә эшли ала, – диде Лариса Маликова.

Без исә каләмдәшләребезгә әле күп еллар дәвамында укучыларының тугры дуслары булып, аларны сөендереп яшәүләрен телибез!

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Телнең киләчәген язучылар

Монда катнашу – үзе җиңү! Татар теле һәм әдәбиятыннан халыкара олимпиадада катнашканнардан бу сүзләрне еш ишетергә туры килә. Быел ул унынчы мәртәбә узды. Аның бүләкләү тантанасына без дә барып, җиңүчеләр белән аралашып кайттык.

12 меңләп катнашучы арасыннан сайлап алынган 500 тирәсе укучы һәм студент дүрт көн дәвамында татар мохитендә кайнап, татар теле һәм әдәбиятыннан белемнәрен тикшерде. «Иң-иң»нәренең исемнәрен исә «Сәйдәш» мәдәният үзәгендә атадылар. Олимпиаданың призерларына – 20 мең, җиңүчеләргә – 25 мең, гран-при ияләренә 30 мең сумлык акчалата бүләк бирелде.

Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе җитәкчесе Марат Әхмәтов сүзләренчә, сәхнәдә басып торган һәм залда утыручы һәр катнашучы белән горурланырга була.

– Татар теле – дәүләтле, горур халыкның искиткеч әдәби, нәфис теле. Бу телне белгәнгә, аның белән кызыксынганга, татар теле өчен янып-көеп яшәгәнгә һич кенә дә үкенергә ярамый. Әлеге киң колачлы чарага телебез өчен чын күңелдән җан атучы укучылар һәм студентлар җыелган. Араларында башка төбәкләрдә, чит илләрдә яшәп тә туган телләрен күз карасыдай саклаучылар бар. Бу бәйге телебезнең гыйльми мирасын ачарга мөмкинлек биргәндер, һәр катнашучы олимпиададагы сораулар аша телнең никадәр тирән тарихлы һәм бай икәненә тагын бер мәртәбә инангандыр. Катнашучыларга да, остазларга да – һәммәгезгә ихлас рәхмәт! Сезнең кебекләр булганда, телебезнең киләчәге дә булыр.

Татарстанның мәгариф һәм фән министры урынбасары Минзәлия Закирова чыгышын мөгаллимнәргә рәхмәт сүзләреннән башлады.

– 2023 ел ил күләмендә Укытучы һәм остаз елы дип игълан ителде. Бу җәһәттән уку-укыту эшчәнлегенә шактый гына яңалыклар кертелде. Шушы үзгәрешләрне йөрәкләре аша уздырган укытучыларга рәхмәт! Бүгенге бәйрәм – сезнең хезмәтегезнең чираттагы җимеше, – диде ул.

Гран-прига өч кеше лаек булды. Алар – Казахстаннан Азат Әхмәтҗанов, Башкортстаннан Ләйсән Галимова һәм Татарстаннан Ихтыяр Кыямов.

– Без, татар яшьләре, телебезне белергә һәм сакларга тиеш. Бүген без шушы матур телебезнең киләчәген язабыз, – диде Азат Әхмәтҗанов. – Әлеге олимпиадада өченче мәртәбә катнашуым. Башка елларны онлайн гына кушылсам, быел менә Казанга килергә насыйп булды. Бик яратам Татарстан башкаласын. Укуымны шушында дәвам иттерергә хыялланам.

Азат икътисад өлкәсендә белгеч булырга әзерләнә, өченче курста укый. Казахстанда уза торган татар чараларын калдырмый икән.

– Безгә татар телендә сөйләшү чагыштырмача җиңел. Чөнки татар теле белән казах теле бик охшаган. Өстәвенә безнең өлкәдә (Азат – Казахстанның Актүбә өлкәсеннән. – **Авт.**) 9264 татар яши, татар-башкорт мәдәни үзәге бар. Анда уза торган очрашулар да туган телне онытмаска ярдәм итә, – дип сөйләде Азат.

Татар мохитендә яшәп тә, туган телләрен белмәүче яшьтәшләренә бераз булса да уйланырга киңәш итә ул. Күбрәк татар китаплары укырга, моңлы татар җырларын тыңларга, ә иң мөһиме – сөйләшергә кирәк, ди.

Икенче җиңүче Ләйсән Галимова мондый чараларның әһәмияте турында әйтте:

– Бу үрләргә менәргә ярдәм иткән, туган телемә, туган җиргә сөю, хөрмәт тәрбияләгән әти-әниемә, дәү әниемә, хөрмәтле укытучыма, Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгына зур рәхмәт! Мондый чаралар булганда, телебезнең киләчәге матур булыр.

Ихтыяр Кыямов та Ләйсәннең сүзләрен куәтләде:

– Әлеге олимпиадада тәүге тапкыр гына катнашуым. Ләкин менә нинди нәтиҗә ясарга өлгердем: монда татар телен, халкын чынлап сөйгән милләтпәрвәр балалар җыелган. Дүрт көн дәвамында алар белән бергә кайнаганда шуны аңладым: милләтебезнең киләчәге матур. Фатих Әмирхан сүзләре белән әйтсәк, «Якты истикбаль бар!» – диде ул.

Тамаша залында катнашучылар арасында утырганда, аларның үзара русча аралашуын ишетеп, кәеф кырылган иде. Гран-при ияләре белән сөйләшкәннән соң рәхәт булып китте тагын үзе…

ТАТАР ТЕЛЕ БУЕНЧА X ХАЛЫКАРА ОЛИМПИАДАДА
Татарстан мәктәпләрендә **8–11** сыйныфларда белем алучы **220** укучы, Россиянең төрле төбәкләрендәге белем бирү оешмаларында һәм якшәмбе мәктәпләрендә **8–11** сыйныфларда белем алучы **220** укучы, Татарстан һәм Россия вузларында белем алучы **49** студент, Казахстан, Кыргызстан, Азәрбайҗан, Үзбәкстаннан килгән **11** укучы һәм студент катнашкан.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

НӘРСӘ УЛ ЯСАЛМА АКЫЛ?

Без әле кая барабыз?

Соңгы вакытта ясалма акыл һәм ул ачкан мөмкинлекләр турында шау-шу бара. Чит илләрнең һәм Россиянең матбугат чаралары ул ачкан мөмкинлекләргә хәйран кала, ә айтишниклар, бер-берсен уздырып, ачышлар ясый, аны гамәлдә кулланырга омтыла. Моның өчен миллиардлаган сум акча тотыла. «Ясалма акыл» (AI) дигән нәрсә ул – адәм акылы таләп ителгән гамәлләрдә компьютерларны һәм башка җайланмаларны куллану мөмкинлеге бирүче технологик ысуллар берлеге.

Ясалма акыл турындагы хыял кешедә борынгы заманнарда ук булгандыр. Мифларда, легендаларда, әкиятләрдә һәр адымда кешегә ярдәм итүче акыллы затлар бик еш очрый бит. Ләкин аны чынга ашыру буенча узган гасыр урталарында гына ныклап шөгыльләнә башлыйлар. 1956 елда Дармут колледжында Джон Маккарти уздырган конференция моның рәсми башлангычы булып санала. «Ясалма акыл» (artificial intelligence, AI) дигән термин да шунда кабул ителә. Аннан соңгы чорларда да эшчәнлек тукталмый, ясалма акылның төрле модельләре, алгоритмнары барлыкка килә. Ә интернет һәм алдынгы технологияләр үсеш алу белән катлаулырак, төгәлрәк алгоритмнар төзү мөмкинлеге туа һәм ЯА кискен үсеш ала.

vk.com

Бүген ул күз иярмәс тизлек белән үсә һәм медицина, транспорт, финанс, җитештерү һ.б. өлкәләрдә кулланыла. Әйтик, сәламәтлек саклау мәсьәләсендә ул тиз арада төгәл диагноз куярга һәм дәвалау алымнары тәкъдим итәргә сәләтле икән. Бу хакта галимнәр үзләре дә шаккатып сөйли.

Хәйран итәрлеге дә бар. Аны төгәллек таләп итүче өлкәләрдә генә түгел, ә сәнгатьтә дә кулланып була бит. Хәер, сәнгатьнең күп төрләре үзләре үк төгәллек таләп итә инде. Сурәт ясау, фотога төшерү, музыка яздыру кебекләре, мәсәлән, математик гамәл шикелле тоела: һәр нәрсәне тиешле микъдарда гына куллануны сорый. Һәм рәхим ит: компьютер барысын да сиңа үзеңнән дә төгәлрәк итеп эшләп бирә ала. Шуңа күрә бүген ясалма акылның фотосурәтләрне, картиналарны чистарту, төсләр белән баету кебек мөмкинлекләре киң кулланыла. Алай гына түгел әле, ул сүз белән тасвирлауны картинага әйләндерү мөмкинлегенә дә ия. Әйтик, син табигать күренешләрен яки кемнеңдер кыяфәтен сурәтләгән текст төзисең, ә компьютер шуны рәсемгә әйләндерә. Яхшы сыйфатлы рәсемгә. Барысы да синең язмаңның төгәллегеннән, сүзләр белән эш итә белү сәләтеннән тора. Гаҗәп бит инде!

Моннан тыш, ясалма акылның видеоязмалар өчен сценарийлар төзү, шуның буенча видео төшерү сәләте дә киң кулланыла. Музыка да яза белә ул. Анысы да хәйран гына килеп чыга икән. Amper дип аталган виртуаль композитор, мәсәлән, тулы бер альбом язган һәм аны 2017 елның 21 августында җырчы Тэрин Саузерн белән берлектәге концертта тәкъдим иткәннәр. Бу – музыкаль альбомны кеше язмаган беренче очрак.

Лондонның Jukedeck компаниясе уйлап чыгарган ясалма акыл да сез теләгән, кәефегезгә туры килгән музыканы берничә секунд эчендә хасил итә. Музыка язуда үз көчеңне компания сайтында сынап карарга мөмкин. Бик күп җырчылар виртуаль композитор язган аккомпанементка эшләргә ярата, алар фикеренчә, беркайчан да арымаган, музыка турында барысын да белгән партнер белән эшләү бик уңайлы.

Тавыш белән эшләү сәләте болай гына бетми әле. Ул тавышны – текстка, текстны тавышка әйләндерә белә. Хәтта билгеле бер текстны үзеңнең яки башка кешенең тавышы, сөйләү манерасы белән дә укытырга мөмкин. Әйтик, хикәя язасың да, аны инглиз теленә әйләндереп, берәр илнең Президенты яки бүтән танылган кешесе тавышы белән укытасың. Кызык кына килеп чыга. Текст өлкәсендәге тәҗрибәләр турында мин соңрак сөйләрмен, чөнки ул миңа әйтеп бетергесез дәрәҗәдә кызык тоелды. Әлегә шуны гына әйтергә мөмкин: ул язган яки тәрҗемә иткән мәкаләләр бүген интернет-кибетләрдә, социаль челтәрләрдә, һәртөрле сайтларда киң кулланыла. Робот язган романның Япониядә узган әдәби конкурсның беренче турына үткәнен дә беләсездер. Болар инде – берничә ел элек булган хәлләр, бүген AI бөтенләй башка дәрәҗәдә.

Гомумән, ясалма акылның нәрсәләргә сәләтле икәнен аны уйлап табучылар да, төрле гамәлләргә өйрәтүчеләр дә тулысынча бәяләп бетерә алмый. Чөнки ул туктаусыз өйрәнә, камилләшә. Кайбер белгечләр фикеренчә, ул хәтта үзлегеннән өйрәнүгә дә сәләтле икән. Шуңа күрә аның нинди юнәлештә үсеш алачагын күз алдына китерү дә авыр.

Аның бик файдалы яклары да, шикшөбһә уята торган сыйфатлары да җитәрлек. Facebook үткәргән тәҗрибәләр вакытында, мәсәлән, Боб һәм Элис дигән ике робот инглиз телендә үзара гәпләшергә тиеш булган. Ләкин көтмәгәндә алар бөтенләй бүтән, беркем дә белми торган телдә аралаша башлаган. Һәм иң кызыгы: алар бер-берсен аңлаганнар. Бу аларның Гугл-тәрҗемәчедәге мәгълүматлар нигезендә үз телләрен булдыруга да сәләтле икәнен күрсәтә.

Кызык хәлләр дә булгалый. Tencent QQ компаниясе, клиентлар белән аралашу, аларның сорауларына җавап бирү өчен, ясалма акыл нигезендә бот (виртуаль робот) ясый һәм аны Кытайдагы ике кибеткә тәкъдим итә. Клиентларның берсе шунда: «Яшәсен коммунистлар партиясе!» – дигән язу калдыра. Робот болай дип җавап бирә: «Шулкадәр җитешсезлекләре булган һәм коррупциягә баткан сәяси система чынлап та кирәк дип уйлыйсызмы?» Шундыйрак берничә фикердән соң ботның эшен туктатырга мәҗбүр булганнар.

Ни генә әйтсәң дә, ясалма акыл үсештә һәм аннан баш тарту мөмкин түгел. Бәлки, кирәкмидер дә. Бик күп өлкәләрдә ул кешегә алыштыргысыз ярдәмче була бит. Шул ук вакытта кешене тормыштан кысрыклап чыгару мөмкинлеген дә онытмаска кирәк. Хәер, алар турында алдарак сөйләшербез…

Марат КӘБИРОВ

Сак бул!

Сине өйдә көтәләр!

Иртән чыгып киткәндә, кичкә өйдә көтүләрен онытмаска кирәк! Көнебезнең күп өлеше эштә үтә. Эш урынының куркынычсызлык таләпләренә туры килүе дә, сәламәтлек өчен уңайлы булуы да мөһим. Һәр эш бирүче үзенең хезмәткәрен кайгыртырга, аңа тиешле шартлар тудырырга тиеш. Хезмәтне саклау көне уңаеннан оештырылган журналистлар белән очрашуда Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова шулай диде.

– Быел өч айда Дәүләт хезмәт инспекциясенә эш урыннарына бәйле бәхетсезлек очраклары турында 49 хәбәр килде. Шуның 17се үлем белән тәмамланган. Узган елның бу вакытында 51 хәбәр алынган, шуларның 21ендә кешеләрнең гомере өзелгән иде. Без саннарның кимүен күзәтәбез. Әмма һәлак булган кешеләрнең гаиләләре кызганыч. Алар бит туендыручысыз, ятим кала. Әнә шуңа да эш урыннарында күңелсезлекләргә юл куймаска кирәк, – ди министр.

Эльмира Зарипова сөйләвенчә, иң куркыныч һәм җәрәхәт ала торган өлкәләр дип транспортировка, саклау, эшкәртү, төзелеш санала. Узган ел эштәге имгәнүләрне киметә алганнар. Ә менә сәүдә өлкәсендә имгәнүләр 2,3 тапкыр арткан. Авыл хуҗалыгында да, сәламәтлек саклау оешмаларында да бәхетсезлек очраклары күбәйгән.

– Без 1 апрельдән 1 июньгә кадәр хезмәт урыннарында төрле юнәлештә эшләр алып барабыз. Кайдадыр техник белемнәрне ныгыталар, кайбер оешмада яңадан укыталар, куркынычсызлык кагыйдәләрен искә төшерәләр, анкеталар тутырталар. Кайбер министрлыклар да бу ике айда безгә кушыла. Техниканың төзеклеге тикшерелә. Эш бирүчеләр арасында хезмәт урыннарын саклауга бәйле бәйге дә игълан ителде. Кыскасы, эш урыннарында уңайлы шартлар тудырыла, – ди министр.

Сүз уңаеннан, республиканың бер зур оешмасы җитәкчесе, эш урыннарында имгәнүләр булмасын өчен, катгый таләпләр куйган. Анда баскычтан менгәндә дә, төшкәндә дә махсус тоткычларга тотынасы. Коридорларда телефоннан сөйләшергә ярамый. Аяк астына карамыйча, абынып егылулар булмасын өчен, хезмәткәр эш урынында телефонын махсус тартмага салып куя.

Министр исә, күп әйбер кешенең үзеннән дә тора, дигән фикердә. Бәхетсезлек очракларына кешеләрнең куркынычсызлык таләпләренә бармак аша каравы сәбәпче икән. Күптән түгел бер оешмада кондитер махсус җиһаз белән юасы әйберне кулы белән генә юа. Нәтиҗәдә кул чугы имгәнә. Ашлык эшкәрткәндә бер егет, кызыксынып, карарга дип килә дә, автомат җиһаз аны тартып ала. Төзелештәге егылып төшүчеләрнең күбесе саклык каешларын кимәгән була. Күптән түгел бер ир-ат шул рәвешле егылып төшеп үлә.

«Кешене штраф белән генә куркытып булмый», – ди министр. Үз гомере үзенә кадерле булырга тиеш!

– 2023 ел башыннан хезмәтне саклау һәм имгәнүләрне булдырмауга бәйле 51 җинаять эше кузгатылды. Эш урыннарында кагыйдә бозган 2793 кешегә штраф салынды. Шунысы сөендерә: соңгы 4 айда республиканың 36 районында эш урыннарында имгәнүләр теркәлмәгән, – ди ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

И туган тел, и матур тел...

Үз өемдә – үз телем

«Ватаным Татарстан» газетасының махсус проекты Татарстанда үз өен тапкан төрле милләтләрнең яшәеше, милли гореф-гадәтләре белән таныштыра, бер гаилә мисалында «Туган телне ничек сакларга?» дигән сорауга җавап эзли.

МОРДВА

ДӨРЕС КЫЙБЛА

Тәтеш районы

«Улым, кызым, бу сүзне дөрес итеп әйт, кушымчасын бутыйсың бит». Тәтеш районының Килдеш авылында яшәүче китапханәче Марина Кудашова буй җиткән ул һәм кызын һаман дөресләп тора. Югыйсә алар болай да бик әйбәт сөйләшә. Без барган гаилә – туган телне кадерләп саклый торганнардан. Шулай ук гореф-гадәтләр, олыларга хөрмәт тә алар өчен барыннан да кыйммәтрәк.

Кудашовлар – гап-гади гаилә. Марина Павловна – китапханәче, ә ире Сергей – тракторчы. Антонина әбигә – 80 яшь. Уллары Павел – инженер. Өйләнеп, Ульянда яши. Кызлары Татьяна Тәтеш мәктәбендә тарих һәм җәмгыять белеме фәннәреннән укыта. Күрше авыл егете Александр Карабаевка кияүгә чыккан. Әлегә балалары юк.

Әти-әни өйрәтмәсә, кем?

Соңгы вакытта туган телне өйрәтүне мәктәп – гаиләгә, гаилә мәктәпкә сылтый башлады. Кудашовларда җаваплылыкны башкаларга аудару гадәте юк. Мәктәпне гаепләп тә булмый, чөнки мукшы теле укытылмый. Гомер буе шулай икән. Тик, аңа карап, кеше үз теленнән бизмәгән һәм ничек тә өйрәнү җаен тапкан.

– Беренче чиратта, телне саклау гаиләдән килә. Мәктәптә ана телен өйрәтергә белгеч юк. Балалар киләчәктә туган телен белерме? Монысы бары гаиләдән генә торачак, – ди 49 яшьлек Марина Павловна.

Тел өйрәтү бурычын гаиләдә әти-әнигә генә йөкләү белән килешми ул. Әйтик, аның үзенең әнисе – башка милләттән. Әмма әбисе Евлампия, әтисе, апалары мукшыча сөйләшкән. Шуңа күрә «әни бурычы» дип кенә әйтү яклы түгел.

– Без Тәтештә яшибез. Шәһәргә авылдан килүчеләр булса, алар белән мукшыча сөйләшәм. Туган тел укытучылары семинарга килсә дә, шул телгә күчәм. Миндә читенсенү дигән нәрсә юк. Әлегә балаларыбыз юк. Туса, аларны ана теленнән мәхрүм итмәячәкмен, – дип вәгъдә итә 27 яшьлек Татьяна.

Укый да белми идек

Марина Кудашова 30 ел мәдәният өлкәсендә хезмәт куйган, шуның 25 елын китапханәдә эшли. Алабуга мәдәни агарту училищесыннан соң читтән торып Мордовия институтында белем алган.

– Безне мәктәптә укырга өйрәтмәделәр. Мордваларның Мордовиядә яшәгәнен белә идек. Тик китап, журналлар юк иде. Укый да белми идек хәтта. Беренче тапкыр мордва китабын кулыма училище тәмамлап, китапханәгә эшкә урнашкач тоттым. Берничә китап бар иде. Мин ачып укыдым, әмма берни аңламадым. Аннан китапханәгә журналлар килә башлады. Иҗекләп укырга өйрәндем. Ни өчен дигәндә, сөйләм һәм язу теле бик нык аерыла. Мукшы телендә килеш төшенчәләре тугыз. Укыйм, сүзләр аңлашылмый, биш минут уйлап торам, аннан гына мәгънәсенә төшенә идем. Аннан китапханәдә балалар, өлкәннәр белән укырга өйрәнә башладык. Әбиләр башта, булдыра алмыйбыз, дип каршы килде. Менә шулай өйрәндек, – ди сөйләде Марина Павловна.

Әбисе Евлампия белән үскән ул. Әнисе эштә чакта оныгына әкиятләр сөйләгән, санарга өйрәткән. Марина әйтүенчә, туган телне өйрәнү беркайчан да кыен булмаган. «Тормышта күп очракта туган телемне кулланам. Русча бары телефоннан һәм эшкә кирәк булганда гына сөйләшәм. Балаларыбыз беркайчан да каршы килмәде. Студент вакытларында алар белән телефоннан үз телебездә сөйләштек. Төркемдәшләре янында да читенсенмәделәр. Саранскига баргач, автобуста мукшы телендә сөйләшәм. Аптырап караучылар да бар. Әмма оялмыйм, бу бит – горурлык», – ди әңгәмәдәшем.

Әлбәттә, аны да теленең югала баруы борчый. Балаларын дөресләве дә юктан түгел бит. «Кайчак кушымчаны бутыйлар. Сүзне йә күплек санда кулланалар, йә төртелеп калалар. Юк, алай түгел, дип төзәтәм. Ярар инде, әни, диләр. Дөрес әйтергә кирәк, дип кисәтү ясыйм», – ди.

Дәресләр юк – белгеч кирәк

Әлеге гаиләгә барганчы, балалар бакчасы янында туктап, койма ярыгыннан мәйданчыкта уйнаучы балаларның аралашканын күзәтеп тордык. Алар бер-берсе белән русча аралаша. «Катнаш гаиләләрдә өйдә – русча, мордвалар туган телдә сөйләшәбез», – диде әбиләрнең берсе. Кудашовларның балалары бакчада да, мәктәптә дә туган тел өйрәнмәгән. Алар русчаны бакчага баргач кына

ишеткән. Хәзер тәрбиячеләр сабыйлар белән туган телдә аралашырга тырыша икән, әмма катнаш гаиләдә тәрбияләнү барыбер үзенекен итә.

Килдеш тугызъеллык мәктәбендә бүген 49 укучы укый. Шуларның 10ы – башлангыч сыйныфта. Узган ел аларның саны 14 булган. Людмила Долгова – башлангыч сыйныф укытучысы, «Минем кече Ватаным» берләшмәсе җитәкчесе.

– Кызганыч, туган тел дәрес буларак укытылмый. Ни өчен дигәндә, белгеч юк. Шуңа күрә түгәрәкләрдә генә саклана. Атнага ике мәртәбә икешәр сәгать тарих, мәдәният, гореф-гадәтләрне өйрәнәбез. Әле менә Тукай шигырен мукшы теленә тәрҗемә иттек. Ел саен фәнни конференцияләрдә катнашабыз. Телне онытырга ирек бирмибез. Әмма балалар бик аз аралаша. Катнаш гаиләләрдә оныта баралар. Менә шул борчый, – диде Людмила Долгова.

Әни, гафу ит!

Мордва халкында Май чабу бәйрәменең соңгы көнендә әниләрдән гафу сорау йоласы бар. Бу көнне балалар ике яктагы әниләренә кунакка бара. Кудашовлар да аны үтәмичә калмый. Аның тәртибен безгә дә күрсәттеләр. Каенана Антонина түргә басты. Килен, балалар, оныклар, башларын иеп, аннан гафу сорады. Ул кулына квас тотып, теләкләр теләде, аннан: «Кичерәм, сез дә кичерегез», – диде. Бәлкем, шуңадыр да Кудашовлар нәселендә килен-каенана мөнәсәбәтләре бик әйбәт. Әнә бит каенанасы, Мариналы үз кызым кебек күрәм, ул да мине хөрмәт итә, ди.

Антонина әби дүрт бала үстергән. Кайгылы чагы: ике ай элек олы улын югалткан. Икенче улы Анатолий Нижневартовскида яши. Сергее – авылда. Кызы Наташа Ульяннан кайтып йөри. Балалары ташламый, кыскасы.

Гаилә традициясе

- Марина балаларын Раштуада җырлы шигырьләр сөйләргә өйрәткән. Бу гадәт әбисе заманыннан ук килә. Алар әниләренә ел саен шигырь укый. Кайчак телефоннан гына. Марина исә сөенечтән карталарына акча сала.
  – Күрше Урюм авылында андый гадәт юк. Мин анда баргач, туганнарга керәм дә шигырь сөйлим. Алар аңламыйча тора. Сандыгыңны ач, акчаңны бир, дип шаяртам, – ди Татьяна.
- Пасха алдында «чиста пәнҗешәмбе» көне бар. Ул төнне сәгать 12дә мунча ягалар. Кояш чыкканчы, юынып калырга кирәк. Улы Павелга гел сызлавык чыккан. Мунчада юынгач, башка интектермәгән. Хәзер дә мунчаның сихри көченә ышаналар.
- Пасхага пешерелгән «кулич»ларның берсен икенче елга кадәр сакларга кирәк. Шулай итәләр дә. Һәр бәйрәмгә аерым ризык әзерлиләр. Берсен икенчесенә пешерергә ярамый. Югыйсә күңелсезлек котәргә мөмкин.

– Бөтенесе дә тәртипле булды. Берсе дә каршы әйтмәде. Сергей басудан: «Әни, хәлең ничек?» – дип шалтыратып тора. Киленем дә булыша. 5 оныгым, 4 оныкчыгым бар, – ди.

19 яшьтә кияүгә чыккан Антонина. Ире мәрхүм инде. 40 ел колхозда эшләгән: бозаулар караган, сыер сауган. Чиккән, теккән, бәйләгән. Каенанасын якын күргән. Киленнәргә каената янында яулыксыз йөрергә ярамаган икән.

Әбекәй яшь чагын да искә төшереп алды. Гореф-гадәтләр хәзер элеккегедән аерыла.

– Без Пасханы атна буе бәйрәм иттек. Чирәмдә төрле уеннар уйный идек. Хәзер бит андый нәрсә юк. Ул вакытта яшьләр дә күп иде. Авылдан беркая чыгып китмәделәр. Гаиләдә – 8–10ар бала. Хәзер 1–2дән артыкны тапмыйлар. Бөтенесе институтта укый да шәһәрдә кала. Колхозда эше дә юк инде анысы, –ди.

Туган тел турында да үз сүзен әйтте: «Без бар җирдә мукшыча сөйләшәбез. Минем апам Эстониядә яши. 17 яшендә кияүгә киткән иде. Аның белән гел үзебезчә аралашабыз. Биштә белгән тел сиксәндә дә онытылмый. Шуңа күрә балаларны кечкенәдән өйрәтергә кирәк», – диде.

ВИДЕО

Сәхифәне Сәрия МИФТАХОВА әзерләде.
Фото – Илдар МӨХӘММӘТҖАНОВ

Яшел «аю»лар бәйрәме

Троисын бәйрәменең икенче көнендә мордва халкы Офтонь якафтомат йоласын билгеләп үтә. Урманга барып, өрәңге ботакларыннан киемнәр әзерлиләр. Аю булып киенәләр. Элек ирләр дә әзерләнсә, хәзер урманга хатын-кызлар гына бара. Ирләр бу вакытта кырда. Ул көнне тәрәзә кашагаларын, ишегалдындагы коеларны да яшеллеккә төрәләр. Яшел «аю»лар урам буйлап авылга атлый. Бу вакытта һәр йорт янында табын коралар. Аю бәла-казадан саклый дигән ышану яши. Аюлар һәр йорт янында туктап, маллары артсын, гаиләдә сәламәтлек булсын, дип теләк тели. Әгәр өеңә «урман патшасы» килеп, аны сыйласаң, хуҗаны тыныч, имин тормыш көтә. Бу йола Килдештә һәм Лениногорск районының Кармалка авылында гына сакланган.

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5316 данә
Гомуми тираж – 14278 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 259

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+